СОВЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с.Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)93-1-24, факс (84366)93-1-24. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

# КАРАР

15.06.2020 № 124

**Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Советына депутатлар сайлаулары билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясының 1 өлеше, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Уставының 13 статьясы нигезендә Сеҗе авыл җирлеге Советы **карар бирде**:

1. Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча “Арча хәбәрләре” (“Арский вестник”) район газетасында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (https://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда Курса Почмак авылы,Мәктәп урамы,1нче йорт,Сикертән авылы,Үзәк урам 14 нче йорт,Сеҗе авылы,Мәктәп урамы,25 нче йорт адреслары буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Сеҗе авыл җирлеге урынбасары Н.Б.Сабирҗанова